ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел № 34/7

Шәһәр Советыны 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 26/8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 номерлы карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде

1. Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 26/8 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 08.11.2018 ел № 27/10, 23.05.2009 ел № 31/6 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

- 18 пунктның сигезенче абзацында «300» саннарын «550» саннарына алыштырырга;
- 57 пунктта «һәм төп вазыйфада» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 67 пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

- 41 пунктта «һәм төп вазыйфада» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 52 пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа " сүзләрен төшереп калдырырга;

3) өстәмә белем бирү муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

- 92 пунктта «һәм төп вазыйфада» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 103 пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа" сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге Карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 сентябреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев